**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 июнь № 442

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планы (программасы) турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1029 нчы карары белән расланган 2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планына (программасына) үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планы (программасы) турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1029 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 февраль, 56 нчы; 2016 ел, 17 май, 318 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планына (программасына) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«2016 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте» дигән II бүлекнең «2016 елда хосусыйлаштырылырга тиеш җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр исемлеге» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | | | |
|---|---|---|---|
| «Hotel ULRIKA, s.r.o.»<br>(«Ульрика» отеле» ҖЧҖ)<br>Чехия Республикасы, Карловы Вары | юк | 100 | 100». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\442.docx